ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Әлки муниципаль районы
Чиябаш авыл җирлеге
Советы

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Совет Шибашинского сельского поселения
Алькеевского муниципального района

422886, ТР, Рус Чиябаш авылы,
Тынычлык урамы, 20 й.
Факс (84346) 75-4-37

422886, РТ, Алькеевский район,
с. Русские Шибаши, ул.Мира, д.20
Факс (84346) 75-4-37

**РЕШЕНИЕ** Рус Чиябаш авылы **КАРАР**

2018 елның 24 августындагы 15№

Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 31 маендагы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чиябаш авыл җирлеге буенча бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 14 июнендәге «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә эшләүче сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 481 номерлы карары нигезендә Әлки муниципаль районы Чиябаш җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чиябаш авыл җирлеге буенча бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының авыл җирлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертелде:

даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең, Әлки муниципаль районы Чиябаш

авыл җирлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне түбәндәге эчтәлекле 2.4.1 пункт белән тулыландырырга:

«2.4.1. Авыл җирлеге башлыгына һәм аның урынбасарларына хезмәткә түләүнең дүртенче - җиденче, тугызынчы - уникенче төркемнәренә кертелгән авыл җирлеге башлыгына һәм аның урынбасарларына, айлык акчалата түләүдән һәм еллык түләүле отпускны биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләүдән тыш, ай саен акчалата түләнә торган акчалата бүләкләүләр, тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләүләр, муниципаль хокукый актлар нигезендә премияләр бирелергә мөмкин».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
ТР Әлки муниципаль районы
Чиябаш авыл җирлеге башлыгы: И.З.Сәмигуллин